**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**КАРАР**

«13» ноябрь, 2025 ел          Новотроицк авылы          № 3

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 08 ноябрендәге 41/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР:**

1. 2025 елның 24 ноябрь 16.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Күперле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Калиновка авылында вак таш сатып алу);

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Калиновка авылына керү өчен күперне ремонтлау);

- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Калиновка авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру).

«ӘЙЕ»          «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калиновка авылы, К. Маркс урамы, һәлак булган авылдашларга куелган һәйкәл янында.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы          Д.М. Габделхаева